# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баланлы авыл җирлеге Чия-Түбә авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

19 ноябрь 2022 ел №2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2022 нче елның 19 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез,2023 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең Чия-Түбә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум, моннан тыш, түбәндәге категория гражданнар: 1 һәм 2 группа инвалидлары, Әфганстандагы сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, локаль конфликтларда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге уку формасындагы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме һәм ЛНР һәм ДНР да махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, шулай ук хатынына (иренә), балигъ булган балаларына, алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын» үзара салымын түләүдән азат итүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итәргә;
- Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудырырга;
- Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудырырга, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештырырга;
- Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештырырга,
- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештырырга;
- Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирергә;
- Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашырга;
- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тотарга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, юынтык суны чыгаруны оештырырга;
- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештырырга.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 11 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 7, бу 64% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 5 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 2 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

-Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Баланлы авыл җирлегенең Чия-Түбә авылында узган гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

- 2023 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең Баланлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум, моннан тыш, түбәндәге категория гражданнар: 1 һәм 2 группа инвалидлары, Әфганстандагы сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, локаль конфликтларда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге уку формасындагы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

- ЛНР һәм ДНР да махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, шулай ук хатынына (иренә), балигъ булган балаларына, алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарына» үзара салымын түләүдән азат итәргә.

- Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.

-Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.

-Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру.

-Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру.

-Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.

-Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү.

-Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу.

-Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту.

-Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру.

-Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге.

-Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Баланлы авыл җирлеге башлыгы И.Х.Гыйлфанова